ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 476 2017 елның 25 июле

# 2017 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларының азык-төлек иминлеген тәэмин итү һәм туклануын оештыру максатларында, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының бюджет һәм финанслар департаментына (Логинова С.Н.) гомуми белем бирү оешмалары эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә каралган акчаларны җирле бюджет ассигнованиеләре исәбеннән түбәндәгеләргә үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә:

- уку елы дәвамында бер укучыга бер көнгә 20 сум 60 тиен исәбеннән туклану бәясенең кыйммәтләнүенә өлешчә компенсация.

2. Түбән Кама муниципаль районының социаль яктан якланмаган гаиләләрдәге балаларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү максатыннан, 2017 елга туклану гомуми белем бирү оешмаларының расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә түбәндәге категория укучылар өчен ата-аналар кертемнәреннән азат итәргә:

- ятим балалар һәм опекага алынган балалар;
- инвалид балалар;
-Чернобыль АЭС авариясе нәтиҗәләрен бетерүче гаилә балалары;
- җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган азкеремле, күпбалалы, тулы булмаган гаиләләрдәге балалар.

3. Түбән Кама муниципаль районының шәһәр интернат-мәктәпләренә, «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләренә норматив финанслауны кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 17 декабрендәге 721 номерлы карары нигезендә, туклануга чыгымнарны карап тәрбияләүгә ата-аналар кертемнәре хисабына кайтаруны гамәлгә ашырырга.

4. 2017 елның 1 сентябреннән расларга:

4.1. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның көненә бер тапкыр туклану бәясе:

- 1 - 4 сыйныфларда 55 сум күләмендә;

- 5-11 сыйныфларда 60 сум күләмендә.

4.2. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның көненә ике тапкыр туклану бәясе:

- 1-4 сыйныфларда 80 сум күләмендә;

4.3. Кама Аланы штп урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында һәм авыл гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга көненә бер тапкыр туклану бәясе 1-11 сыйныф укучылары өчен 43 сум 80 тиен.

4.4. Кама Аланының 1 нче мәктәбендә, Кама Аланының 2 нче мәктәбендә укучыларның көненә ике тапкыр туклану бәясе 1-4 сыйныфларда 68 сум 80 тиен.

4.5. Барлык типтагы мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләр өчен мәктәп яшендәге бер тәрбияләнүчегә көненә туклану бәясе 134 сум 35 тиен.

4.6. Махсус (коррекцион) гомуми белем бирү мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләр өчен бер тәрбияләнүчегә көненә туклану бәясе 150 сум 63 тиен.

4.7. Айлык акчалата түләүләр бәясе:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2016 елның 21 сентябрендәге 664 номерлы карары нигезендә, уку чорында бер укучыга көнгә 6 сум 80 тиен;

- Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучылары туклануын оештыру системасына күчү турында» 2017 елның 14 июлендәге 443 номерлы карары нигезендә, уку чорында бер укучыга көнгә 13 сум 80 тиен.

4.8. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен бер тапкыр туклануга ата-ана кертеме суммасы:

- 1 - 4 сыйныфларда 34 сум 40 тиен күләмендә;

- 5 - 11 сыйныфларда 39 сум 40 тиен.

4.9. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен ике тапкыр туклануга ата-аналар кертеме суммасы:

- 1- 4 сыйныфларда 59 сум 40 тиен;

4.10. Кама Аланы штп урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында һәм авыл гомуми белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныф укучылары өчен бер тапкыр туклану өчен ата-аналар кертеме 23 сум 20 тиен күләмендә.

4.11. Кама Аланының 1нче мәктәбендә, Кама Аланының 2 нче мәктәбендә 1-4 сыйныфларда укучы балалар өчен көнгә ике тапкыр туклану өчен ата-аналар кертеме 48 сум 20 тиен күләмендә.

5. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «71 нче күзләре начар күрүче балалар өчен компенсация төрендәге башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең 1-4 сыйныф укучылары өчен көненә дүрт тапкыр туклану бәясе 132 сум күләмендә.

5.1. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле бер укучыга көненә ике тапкыр туклану бәясе 81 сум 84 тиен тәшкил итә («Россия Федерациясендә мәгариф

турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 пункты нигезендә).

6. Гомуми белем бирү оешмаларында социаль якланмаган гаиләләрдән булган балаларны тукландыруны Нигезләмә (кушымта) нигезендә оештырырга.

7. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «2017 елда Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру турында» 2017 елның 16 гыйнварындагы 23 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р. Фәретдиновка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 25 июлендәге
476 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы
гомуми белем бирү оешмаларында социаль якланмаган гаиләләрдән булган
укучыларны тукландыруны оештыру тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү оешмаларында социаль якланмаган балалар өчен түбәндәге категория укучыларга кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру максатларында эшләнде:

- ятим балалар һәм опекага алынган балалар;
- инвалид балалар;
- Чернобыль АЭС авариясе нәтиҗәләрен бетерүче гаилә балалары;
- җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган азкеремле, күпбалалы, тулы булмаган гаиләләрдәге балаларн.

Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан туклану өчен ата-аналар кертемнәреннән азат итү юлы белән социаль якланмаган гаиләләрдәге балаларга адреслы социаль ярдәм 2017 елга гомуми белем бирү оешмаларының расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

2. Туклану шәһәр гомуми белем бирү оешмалары өчен оештырыла:

2.1. 1-4 сыйныф укучылары өчен көненә 34 сум 40 тиен, шул исәптән:

- җирле бюджет акчалары хисабына туклануга субсидияләр - 20 сум 60 тиен.

2.2. 5-11 сыйныф укучылары өчен көнгә 39 сум 40 тиен, шул исәптән:

- җирле бюджет акчалары хисабына туклануга субсидияләр - 20 сум 60 тиен.

3. Туклану авыл гомуми белем бирү оешмалары һәм Кама Аланы поселогында урнашкан гомуми белем бирү оешмалары өчен 1-11 сыйныф укучылары өчен көнгә 23 сум 20 тиенгә кадәр оештырыла, шул исәптән:

- җирле бюджет акчалары хисабына туклануга субсидияләр - 20 сум 60 тиен.

4. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «71 нче күзләре начар күрүче балалар өчен компенсация төрендәге башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 пункты нигезендә түләүсез ике тапкыр туклану белән тәэминителәләр.

5. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында санап үтелгән укучыларны кайнар аш белән тукландыруны оештыру өчен гомуми белем бирү оешмаларында комиссияләр төзелә, аның составына директор, педагогик коллективтан укучыларны тукландыруны оештыру өчен җаваплы һәм ата-аналар комитеты вәкилләре керә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш.

Комиссия уку елы башында һәм алга таба да кирәк булганда:

- тәкъдим ителгән гаризаларны карый һәм укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карарлар кабул итә;
- азкеремле, тулы булмаган, күпбалалы гаиләләрне, аларның торак шартларын тикшерә, аларның матди хәлен, гаиләдәге балалар һәм иждивенецларның санын билгели, укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карар кабул итә, тикшерү нәтиҗәләре белән беррәттән актта, әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә терки;
- категорияләр буенча өстәмә социаль ярдәм алуга мохтаҗ укучылар исемлеген раслый;
- сыйныф җитәкчесе яки озынайтылган көн төркеме тәрбиячесе җитәкчелегендә укучылар тарафыннан ашханәгә төркемләп йөрү графигын эшли;
- бирелә торган төшке ашларның билгеләнгән тәртиптә расланган менюга туры килүен тикшерә.

Комиссия хокуклы:

- җитешсезлекләр белән әзерләнгән ризыкларны сатудан төшерергә;
- медицина хезмәткәре белән берлектә китерелә торган азык-төлек продуктларының туры килү-килмәвен тикшерә, үлчәүне тикшереп тора һ. б.
- тикшерү нәтиҗәләре буенча белем бирү оешмасыннан җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрүне таләп итәргә.

6. Сыйныф җитәкчеләре:

- әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча ата-аналардан яисә аларны алмаштыручы затлардан түләүсез туклану алу өчен гаризалар кабул итәләр;
- гаризаларны алганнан соң өч көн эчендә комиссия каравына җибәрәләр;
- сыйныф укучыларының туклануын категорияләр буенча исәпкә алып баралар;
- укучылар һәм ата-аналар арасында мәктәп укучыларын тулысынча тукландыру кирәклеге турында аңлату эшләре алып баралар;
- барлык сыйныф укучыларының да ашханәгә йөрүен контрольдә тоталар;
- ашханәдә туклану өчен «Мәктәп туклануы» модуле аша түләгәндә сыйныф укучыларына «Укучы картасы»н куллану буенча аңлатмалар бирәләр яки кирәк булганда ярдәм итәләр.

7. Ата-аналар яки аларны алыштыручы затлар тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

8. Гомуми белем бирү оешмалары директорлары:

8.1. Укучылар гаиләләрен тикшерү акты нигезендә категорияләр буенча түләүсез туклану белән тәэмин итү буенча боерыклар чыгара.

8.2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә укучылар исемлеген категорияләр буенча тапшыралар.

9. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе укучыларның туклануын оештыру, азык әзерләү технологиясен үтәү, чыгышын һәм азык-төлек блогларында санитар нормаларны үтәү мәсьәләләрен гомуми белем бирү оешмаларына чыгып тикшереп тора.

10. Әлеге Нигезләмә Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларына кагыла.

Түбән Кама муниципаль районы
гомуми белем бирү оешмаларында
социаль яктан якланмаган гаиләләрдән
булган укучыларны тукландыруны
оештыру тәртибенә
1 нче кушымта

(Форма)

Түбән Кама шәһәренең ______мәктәп _________сыйныфы
укучысы Ф И А ис. _____________________________
гаиләсен тикшерү акты

Түбән Кама шәһәре ___________ 20___ел

___________________________________________________________________
(тулы булмаган, күп балалы, социаль куркыныч хәлдә булган)
_________________________________________________________________ гаилә
(бүлмәләр саны, мәйданы, уңайлыклар булу,
__________________________________________адрес буенча фатирда (йортта) яши.
коммуналка, тулай торак, аренда)
Гаиләдә укучы балалар саны_______, гаиләдә тәрбияләнүчеләр саны___________.
Гаиләнең матди хәле _______________________________________________________.
(яхшы, уртача, уртачадан түбән)
Гаилә әгъзасына җыелма керем тәшкил итә _______ руб. (ата-ана гаризасы буенча).

Ата-аналарның эш урыны, биләгән вазыйфасы, уртача айлык хезмәт хакы:
___________________________________________________________________________.

Өстәмә мәгълүматлар: ____________________________________________
___________________________________________________________________________.

Гаиләнең торак шартларын һәм матди хәлен тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия карар кабул итә:

_______ сыйныф укучысы___________________________________
(Ф.И.А.ис.)
өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаж (мохтаж түгел)
(кирәклесенең астына сызарга)

Комиссия рәисе: _____________________________ ___________________________
(имза, дата) (Ф.И.О.)
Комиссия әгъзалары: __________________________ _________________________
(имза, дата) (Ф.И.О.)
Сыйныф җитәкчесе: __________________________ ___________________________
(имза, дата) (Ф.И.О.)

Түбән Кама муниципаль районы
гомуми белем бирү оешмаларында
социаль яктан якланмаган гаиләләрдән
булган укучыларны тукландыруны
оештыру тәртибенә
2 нче кушымта

(Форма)

Түбән Кама шәһәренең _____ мәктәбе укучыларының
туклануын оештыру буенча комиссиягә

___________________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А.ис.)

___________________________________
(адресы)

гариза.

_____ сыйныфта укучы улыма (кызыма, опекадагы балама)

______________________________________________________________________________,
(Ф.И.О.)

бушлай туклану билгеләвегезне сорыйм.

Гаилә әгъзасына җан башына уртача керем ____________________ сум тәшкил итә.

Өстәмә рәвештә хәбәр итәм:___________________________________________________

______________________________________________________________________________.

Гаилә кеременең күләмен раслаучы документлар кушымта итеп бирелә.

______________________
(Дата, имза)

--------------------------------

Гаризага кушымта итеп бирелә:

1. Гаилә составы турында белешмә.
2. Эш урыныннан хезмәт хакы турында белешмә (соңгы 6 айда).
3. Пенсия, пособиеләр күләме турында белешмә.
4. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгеннән белешмә (эшләмәүчеләр өчен).
5. Күпбалалы гаилә турында таныклык күчермәсе (булганда).
6. Опека һәм попечительлек бүлегеннән белешмә, яисә балигъ булмаганнарны опекага алу турында күрсәтмә күчермәсе.
7. Инвалид балалар өчен МСЭ медицина белешмәсе күчермәсе.
8. Өйләнешү яки аерылышу турында таныклык күчермәсе.
9. Алиментлар алу турында белешмә (булганда).
10. Чернобыль АЭС авариясе нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгының күчермәсе.